**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22,факс (85552)3-44-14, E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № _______

**«2022 елның 1 июленнән «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында»**

1. 2022 елның 1 июленнән расларга (кушымта итеп бирелә):

Гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын, 2022 елның 1 июленнән;

Гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәплəү тәртибе турында нигезләмәне.

2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

Гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары нигезендә финанслау.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисад буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче урынбасары Р.А.Ильясов

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән
«__» _______ 2022 № ____

2022 елның 01 июленнән, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка - 1 елга, сумнарда | автотранспорт чарасының бер километрга үткән юлы ставкасы, сумнарда |
| КАВЗ | 154152 | 38,77 |
| ПАЗ | 153591 | 38,68 |
| ГАЗ «Газель» | 133242 | 31,16 |
| УАЗ | 132789 | 29,69 |
| FIAT | 136630 | 28,02 |
| Peugeot Boxer | 142063 | 27,66 |
| Ford Transit | 142320 | 31,34 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 156063 | 36,63 |

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән
«__» _______ 2022 № ____

Гомуми белем бирү оешмалары укучы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган, автотранспорт чарасың хисап елында фактта узган юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. I муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m төрендәге автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы, километрларда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативы ставкасы бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасы өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру нормативы ставкасы, сумнарда;

$M_m$ - m төрендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлекләрдә;
$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус төре атамасы;
$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.